«ИКЕНЧЕ ИКМӘК» ХАКЫ
Бәрәңге үстерү мәйданын арттырачаклар
> 2

ТАГЫН САЛКЫННАР БУЛЫРМЫ?
Халык синоптигы фаразы
> 2

БЕР КҮРҮДӘ ЯРАТУ
Милләттәшебезнең Сургутта күргәннәре
> 3

КЫЙММӘТКӘ ТӨШКӘН ИР
Бәхетле булу өчен берни кызганыч түгел, хәтта акча да...
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 2 (28775) | Сишәмбе | 11 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Кар явып торганда тимурчыларга эш бетми. Кайберләренең каникулда да кулыннан көрәк төшмәгән. Ялгыз яшәүче әби-бабайларның капка төпләрен ялт иттергәннәр. Бу нинди игелекле балалар икән?

kpfu.ru

РӘХМӘТ ТӨШКЕРЛӘРЕ

КӘҖӘСЕ ТҮГЕЛ, МӘЗӘГЕ КЫЗЫК

Әнә алар Баулы районының Исергәп авылында ялгыз яшәүче 79 яшьлек Зинура апа Гарифуллинаны да сөендереп киткәннәр.

– Яңа елга кадәр буран чыгып, ишегалдын кар баскан иде. Капканы ачып булмагач, аптырагач, мәктәпкә шалтыраттым. Тимурчылар тиз генә килеп, юлны ачты, рәхмәт төшкерләре. Югыйсә өйдә генә утырырга туры килер иде. Без – өлкәннәр өчен күп кирәкми. Бер яхшы гамәл, бер җылы сүз җитә, – ди Зинура апа. – Тимурчылар булганда, күңел тыныч. Ялгыз яшәүче карт-карчыклар һәрвакыт башкалар ярдәменә мохтаҗ. Дәрес, хәзер йортлар җылы, өйдә мөмкинлекләр дә бар. Әмма кары явып тора бит. Аны көрәргә кирәк. Идән юып, тузан сөртүләре дә – зур файда.

Исергәп мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Алисә Гарифуллина әйтүенчә, мәктәптә 80 бала укый.

– Авылыбыз зур, 300дән артык хуҗалык исәпләнә. Бүген авылда бер сугыш ветераны, 12 тыл ветераны яши. Шулай ук авылдагы хезмәт ветераннары, лаеклы ялда булган укытучыларга да ярдәм итәбез. Һәр сыйныфка берәр урам беркетелгән. Әйтик, 9 нчы сыйныф укучылары яңа ачылган чишмәне тәртиптә тота. Булдыра алганча, булышырга тырышалар. Күбесенә ярдәм дә кирәкми, социаль хезмәткәрләр билгеләнгән. Әмма игътибарның артыгы булмый. Язкөз айларында «Игелек марафоннары» уздырабыз. Бәйрәмнәрдә өлкәннәрне котлап, открытка, кәнфит кебек күчтәнәчләр алып барабыз. Балалар белән бергәләп чәй эчәләр, – ди Алисә Гарифуллина. – Әби-бабайлар йортларына балаларны кертергә шикләнми. Бигрәк тә күрше-тирәдә яшәүче, кечкенәдән белгән укучыларны билгелибез. Шуңа күрә балаларга ышаналар. Тимурчылар тузан сөртә, келәм кага, идән юа. Мондый отрядлар кирәк. Яшьләр миһербанлы булырга, олыны олы итеп, хөрмәтләргә өйрәнә. Юлда очраганда, әби-бабайлар укучылар ярдәме өчен безгә рәхмәт әйтәләр. Андый сүзләрне ишетү бик рәхәт.

Балык Бистәсе районының Күгәрчен мәктәбендә дә игелекле балалар тәрбияләнә. Алар – әби-бабайларның уң куллары. Мәктәп директоры Марсель Мингарипов әйтүенчә, авылда тимурчылык хәрәкәтенең беткәне дә юк, бу чылбыр беркайчан да өзелмәгән. Мәктәптә биш авылдан 87 бала укый. Яшьләр оешмасы әфган сугышында һәлак булган авылдашлары Равил Гыйниятуллин исемен йөртә. Әлеге укучылар төрле эшләрдә булыша. Лаеклы ялга киткән укытучылар, техник хезмәткәрләрне дә онытмыйлар. Авылга Казаннан «Игелек волонтерлары» да килә. Алар белән төрле чаралар уздыралар.

– Без эшләп үстек, бер җиребез дә кителмәде. Хезмәт балаларны тәрбияли. Өйдә дә балаларга эшне гел кушып кына торабыз. Берни эшләмичә үскән баланы күз алдына да китерә алмыйм. Күгәрчен балалары тырыш. Мәктәп яны бакчасында җәен практика үтәләр. Әби-бабайларга булышырга дәрестән соң баралар. Монда барлык 5–11 сыйныф укучылары да катнаша. Һәр сыйныфка 2–3 әби-бабай туры килә. Кайберләре кышка балалары янына яшәргә китә. Тимурчылар кыш көне кар көри, язын канау казый, түбәләрдән кар төшерә, җәен җыештыралар. Бер генә әти-әнинең дә каршы килгәне юк. Әлбәттә, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтисе. Шуңа күрә сыйныф җитәкчеләре күз-колак була. Авыл уртасында сугышта катнашкан авылдашлар истәлегенә һәйкәл куелды. Укучылар ел дәвамында аны тәртиптә тота, Равил Гыйниятуллин каберен чистартып торалар, – ди директор Марсель Мингарипов.

Балтач районының Нөнәгәр мәктәбе укучылары ярдәмгә мохтаҗлар турында кышкы каникулда онытмаган. Педагог-оештыручы Энҗе Вафина әйтүенчә, алар Чутай, Нөнәгәр авылларындагы авыру, ялгыз кешеләргә шефлык итә. Мәктәптә 92 бала белем ала. Шефлык итүгә узган уку елында ныклап тотынганнар.

– Радик Муллагалиев 20 ел буе урын өстендә, үзе генә яши. Аның да хәлен белеп торабыз. Тумыштан авыру булган Нурия апа янына бардык. Фрит абый Низаметдиновка да кердек. Каникул заяга узмады. Тимурчылар – 6–7 нче сыйныф укучылары. Алар дүрт кешегә булыша, һәйкәлне тәртиптә тота. Әйтмичә барган юк, алдан хәбәр бирәбез. Шуңа күрә, карны кем көрәде икән, дип аптырап йөрмиләр. Социаль хезмәткәрләре булса да, ялгызларга ярдәм һәрвакыт кирәк. Балалар күңеле дә йомшарып китә. Өлкәннәр рәхмәтләр әйтеп озатып кала, – ди Энҗе Вафина.

Азнакай районында яшәүче Алсу апа Габделхаковага 76 яшь булса да, ул ярдәмгә мохтаҗ түгел. Элеккеге укытучы 2008 елдан бирле бушлай социаль проектларда катнаша. Олысына да, кечесенә дә булышырга тырыша. Ярты ел элек Чаллыдан Азнакайга күченеп килгән. Алсу апа фикеренчә, яшьләрне тимурчылыкка заманча алымнар белән тартырга кирәк.

– Ялгыз яшәсәм дә, шөкер, үз көчемдә. Кушучысы булса, башка әби-бабайларның карын көрәргә каршы килмәячәкмен. Тик куар-код булмагач, еракка чыгып йөреп булмый шул. Азнакайда бөтен җирдә чисталык, тәртип. Күпкатлы йортта яшим, иртүк кар көрәлгән, – ди ул. – Хәзерге заман балалары үзләренә кызык булган нәрсәне генә эшли. Бернәрсәне дә мәҗбүриләп тагып булмый. Шул ук тимурчылыкка да яңа сулыш өрергә мөмкин. Кушу гына түгел, кызыксындырырга кирәк. Әле беркөнне генә бер тапшыруда пилмәнне генә дә әллә ничә төрле итеп бөгеп күрсәттеләр. Шул ук карны да төрлечә итеп көрәп була. Карны көрәүне уен формасында оештырсыннар. Бүген суны краннан агызып эчәбез. Әгәр өлкәннәргә чишмәдән су алып кайтсалар, берсе дә каршы килмәс иде. Балаларга аны көянтә-чиләкләр белән алып кайту кызык булыр иде. Балага кәҗәсе түгел, мәзәге кызык. Интернетта утырганчы, балаларны эшкә җәлеп итүнең яңа формаларын эзләргә кирәк. Яшьләрне милли традицияләрне сакларга өйрәтәсем килә.

Сәрия МИФТАХОВА

Түземлек бирсен сезгә, туганнар!

10 гыйнварда Казахстанда чуалышларда һәлак булганнар истәлегенә матәм көне узды. Бу җәһәттән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Казахстан Парламенты Сенаты Рәисе Мәүлен Ашимбаев һәм Парламент Мәҗлесе Рәисе Нурлан Нигъмәтуллин исеменә кайгы уртаклашу телеграммасы җибәрде.

«Татарстан Дәүләт Советы депутатлары, Халыклар ассамблеясы советы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Казахстан Республикасындагы фаҗиганең күп корбаннар китерүенә бәйле рәвештә кайгы уртаклашу сүзләрен җиткерәм, – диелә Татарстан парламенты җитәкчесе телеграммасында. – Тугандаш Казахстаннан кораллы бәрелешләрдә Казахстан Оборона министрлыгының хәрби хезмәткәрләре, хокук саклау органнары хезмәткәрләре, гади кешеләрнең һәлак булуы турында кайгылы хәбәрләрне зур кызгану хисе белән күзәтеп барабыз. Ил эчендәге сәяси вазгыятьнең тиз генә вакыт эчендә тотрыклылануына ышанабыз. Һәлак булганнарның якыннары һәм туганнарына – бу авыр көннәрне үткәреп җибәрү өчен түземлек һәм бик зур көч, зыян күрүчеләргә – тизрәк савыгуларын, Казахстандагы барча кешегә тынычлык һәм татулык телибез».

Дәүләт Советы депутатлары Айрат Зарипов һәм Римма Ратникова да Казахстан Республикасының Казандагы Генераль консуллыгына барып, бу ил халкының кайгысын уртаклашты.

Ялларда Казанда 446 бала туган

Татарстан башкаласында 1 гыйнвардан 10ына кадәр барлыгы 446 бала туган. Сәламәтлек саклау министры урынбасары – шәһәрнең сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы Владимир Жаворонков әйтүенчә, бәйрәм арасында 257 малай һәм 189 кыз дөньяга аваз салган.

Яңа елда – курантлар сукканнан соң 1 минут узгач, башкалабызда беренче булып Медицина университеты клиникасында 2,9 кило авырлыктагы кызчык дөньяга килгән. Нарасыйның әти-әнисе – Яшел Үзән районы үзәк хастаханәсендә эшләүче табиблар.

1 гыйнварда Татарстанда барлыгы 39 бала: 23 малай һәм 16 кыз туган.

Төзиләр һәм төзекләндерәләр

Татарстанда быел өч программа: күпфатирлы инвестицион торак төзү, Дәүләт торак фонды һәм шәхси торак төзү программалары буенча барлыгы 2 миллион 755 мең квадрат метр торак мәйданын файдалануга тапшырырга кирәк булачак. Кайбер категориядәге кешеләрне торак белән тәэмин итү буенча 4 программаны үтәү күздә тотыла. Шулай итеп, агымдагы елда 600 ятим балага, 5 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләп үстерүче 40 гаиләгә, мәҗбүри күченүчеләр, Ерак Төньяктан күченүчеләр һәм «чернобыльче»ләр арасыннан 7 кешегә бушлай фатирлар (барлыгы 1 миллиард 228,6 миллион сумлык) биреләчәк.

2022 елда капиталь төзекләндерү программасында 42 муниципаль берәмлек катнаша. Программага 769 йорт кертелгән. Капиталь төзекләндерүгә 6 миллиард 441 миллион сум акча тотылачак.

Хәвефле яллар

Утка да, юлга да ышаныч юк

Яңа елны тынычлык теләп башласак та, бәйрәм яллары шактый хәвефле узды. Коткаручыларга да, хокук сакчыларына да тик утырырга туры килмәде.

mchs.gov.ru

Яңа 2022 елның беренче сигез көнендә Россия юлларында 2 меңләп юл һәлакәте теркәлгән. Аларда 230 кешенең гомере өзелгән, 700 кеше имгәнгән. Республикада бу чорда 71 юл һәлакәте теркәлгән. Татарстанның ЮХИДИ идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, 17 кеше үлгән, 102 кеше имгәнгән. 1 гыйнварда Казан – Ульян юлында ике җиңел машина бәрелешеп, 3 кешенең гомере өзелде. Икенче көнне Тукай районындагы авариядә 2 кеше һәлак булды. 7 гыйнварда Әлмәт районында Казан – Оренбург трассасында дүрт кешенең гомере өзелде. Ульяновск өлкәсендә килеп чыккан юл һәлакәтендә Татарстанның «Энергия» регби клубында шөгыльләнгән ике яшь спортчы һәм тагын берсенең әнисе һәлак булды. Бәйрәм ялларының соңгы көнендә Чаллыда җәяүлеләр кичүеннән чыкканда машина астында калып, 15 яшьлек малай җан бирде.

Берничә көн элек Чаллы шәһәре бер телгә кергән иде инде. Шәһәр уртасында 6 нчы номерлы трамвай янып бетте. Бәхеткә, зыян күрүчеләр юк. Якшәмбе көнне Казанның Осиново бистәсендә килеп чыккан янгында исә бер ир-ат зыян күргән. Аның тәненең 30 проценты пешкән. Сүз уңаеннан, Татарстанда 31 декабрьдән 9 гыйнварга кадәр 112 янгын очрагы теркәлгән. Фаҗигаләрдә 8 кешенең гомере өзелгән, тагын 8е зыян күргән. Былтыр утта һәлак булучылар 4 кешегә күбрәк булган. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең матбугат хезмәтеннән хәбәр итүләренчә, Яңа елның тугыз көнендә Татарстанда сөрем газы белән агулануның барлыгы 6 очрагы теркәлгән. Аларда 2 кешенең гомере өзелгән, тагын 11 кеше зыян күргән. Узган елның шушы ук чорында республикада сөрем газы белән агулануның 3 очрагы теркәлгән булган.

5 гыйнвар көнне Арчаның Төбәк-Чокырча авылындагы шәхси йортларның берсендә газ шартлады. Йортка газ кертелмәгән, казан баллонга тоташтырылган булган. Шартлаудан зыян күргән ике ир-ат белән бер хатын-кыз район хастаханәсенә озатылган.

Бәйрәм ялларында юл һәм ут корбаннарына гына түгел, боз корбаннарына да ярдәм итәргә туры килде. Берничә көн элек коткаручылар Чулманга балыкка киткән җиреннән адашкан 70 яшьлек картка ярдәм итте. Аңа кадәр Кама Тамагында өши язган тагын бер балыкчыны коткарганнар. Техникага да ышаныч юк. Хәтерләсәгез, 5 гыйнвар көнне Лаеш районының Зеленый Бор авылында трактор һәм аңа ярдәмгә килгән экскаватор боз астына төшеп киткән иде. Берничә көн элек Чулман елгасы кичүендә 35 тонналы йөк машинасы батты.

Сүзгә-сүз

Сәйдә МӨХӘММӘТҖАНОВА, җырчы:

Үзебездән соң бай мирасыбызны калдырырга, татар халык җырларының чынлыкта ничек яңгырарга тиешлеген күрсәтергә телибез. Бәлки, алар яшьләр өчен кызык та булмас. Әмма фикерләү дәрәҗәсе өлгергәч, алар татар халык җырларының зур хәзинә булуын, аны киләсе буынга тапшырырга кирәк икәнен аңлаячак.

(Kazanfirst электрон басмасына әңгәмәсеннән)

ЯҢА ЕЛГА – ЯҢА ВӘГЪДӘЛӘР

Күбрәк китап укырга, спорт белән шөгыльләнергә, шәхси тормышын үзгәртергә. Россиядә яшәүчеләр 2022 елга шундыйрак вәгъдәләр белән аяк баскан. Бу хакта «SuperJob» хезмәте оештырган сораштыру нәтиҗәләре сөйли.

Белем арттырачакмын һәм китап укыячакмын	30%
Якыннарым белән ешрак аралашачакмын	27%
Шәхси тормышны көйләячәкмен	26%
Спорт белән шөгыльләнә башлаячакмын	25%
Яраткан шөгылемә вакыт табачакмын	23%
Бернәрсәне дә үзгәртмәячәкмен	6%

Казанда яшиләр ярдәмчел кешеләр

Казан халкы үзенә хас булган сыйфатларны атап үткән. Superjob тикшеренү үзәге үткәргән сораштыруда катнашучыларның 40 проценты фикеренчә, Татарстан башкаласында яшәүчеләр ярдәмчел һәм кешелекле. Россиянең башка зур шәһәрләре арасында әлеге сыйфат буенча иң зур күрсәткеч бу. Респондентларның 17 проценты – казанлыларның хезмәт сөючән, 13 проценты кунакчыл булуларын күрсәткән. Сүз уңаеннан, башка бер генә шәһәрнең дә үзен кунакчыл дип санамавын әйтеп үтәргә кирәк. Краснодарда (сораштыруда катнашучыларның 29 проценты) һәм Түбән Новгородта (28 процент) яшәүчеләр, Казан халкы кебек, ярдәмчел булуларын әйткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

НИШЛӘДЕҢ СИН, КАЗАХСТАН?

2022 елның Казахстанда зур давыл белән башланып китүе дөньякүләм вакыйга буларак кабул ителде. Халык саны артык зур булмаса да, территориясе байтак мәйданны иңләп торучы бу ил геосәяси яктан тиңсез әһәмияткә ия. Бу мәйданда дүрт зур сәясәт уенчысының мәнфәгатьләре кисешә.

Бу – Көнбатыш инвестицияләре мул коелган төбәк, анда җитештерелгән чималдан да нигездә Көнбатыш илләре файдалана. Россия белән аны иң зур коры җир чиге генә түгел, уртак икътисади бәйләнешләр дә тыгыз бәйләгән. Соңгы вакытларда Кытай (шулай ук чиктәш дәүләт), казах иленә үзенең инвестицияләрен арттырып, анда Көнбатышны кысрыклый башлады. Төркия бу төбәктә мөстәкыйль дип әйтерлек үз уенын алып бара. Шуңа күрә дала илендә 2 гыйнварда башланып киткән вакыйгалар зур кайтаваз бирә һәм бирүен дәвам иттерәчәк.

Бу язмада без анда барган хәлләрнең төп уенчыларына һәм этәрүче көчләренә бәя бирмибез. «Фетнәне кем оештырды, ул кемгә файдалы иде?» дигән сорауларга җаваплар күп һәм төрле, аларның берсе ягына да авышмыйбыз. Чөнки, бердән, вакыйгаларның асылын бөтен нечкәлекләре белән белмибез, ә безгә килеп ирешкән рәсми һәм идән асты хәбәрләре – мәгълүмат кылычын болгап, зур сугыш алып бару нәтиҗәсе генә. Дәүләтнең Милли Куркынычсызлык Комитеты рәисе кулга алынган һәм аның урынбасарлары эштән читләштерелгән икән, сүз дәүләт түнтәрелешенә омтылыш турында бара, монысына шик юк.

Без башка әйберләргә игътибарны күбрәк юнәлтәбез. Казахстан – табигый чималларга гаҗәп бай ил. Анда дөнья күләмендә табылган уранның 42 проценты җитештерелә. Бу уран чыгару буенча икенче, өченче, дүртенче урыннарда торган Канада, Австралия һәм Намибиянең бергә җитештергән ураны кадәрле. Сүзнең нинди стратегик чимал һәм нинди байлык турында баруын аңлый торгансыздыр инде? Моннан тыш нефть чыгару буенча ил – 12 нче урында, күмер байлыклары ягыннан – 8 нче, асбест җитештерү күләмен караганда – 2 нче, хром чыгаруда – 3 нче, алтын табу буенча – 10 нчы, титан җитештерүдә – 4 нче урында. Моннан тыш исемлеккә кермәгән шундый металлар бар: казахлар, аларның бер шырпы кабы күләмендәгесен сатып, йөзәр мең доллар акча ала. Ит, сөт, ашлык җитештерү өчен иге-чиге күренмәгән җирләрен инде әйтеп тә тормыйк. Ә илдә бары тик 19 миллион кеше яши. Менә шушы ил фәкыйрьлек чигендә гомер сөрә, халкы матди тормышыннан канәгать түгел. Бәяләр сикереше, хезмәт хакларының бик чикле булуы массаларның тәмам җелегенә үткән. Мотор газына яңа ел башыннан бәяләрнең ике тапкыр күтәрелүе (безнең акча белән исәпләгәндә 10 сумнан 20 сумга) халыкның протест мәйданына чыгуына китерде. Казах олигархлары, «баканы акрын утта пешерәләр» дигән кагыйдәне онытып, учакка кискен ялкын өстәде. Шуннан соң мәйданга бөтенләй көтелмәгән уенчылар аяк басты. Протест элиталар арасындагы көрәш төсен алды, бик күп кан коелды. Урта Азиядәге зур мәйданда, чынлыкта, глобаль системаның тектоник плитәләре бәрелеште һәм бу киләчәктә планета күләмендә вазгыятьнең ничек булачагына ишарә итә.

Россиядә

«ОМИКРОН» КИЛЕП ҖИТӘ

Россияне Казахстан белән уртак чик һәм уртак икътисади багланышлар гына түгел, халыкларның матди хәлендәге охшашлыклар да якынайта. Казахлар матди яктан бездән бик аз гына түбәндәрәк яши. Шул ук мотор газына бездә бәяләр төрле төбәкләрдә 26 сумнан 37 сумга кадәр йөри. Җитмәсә Россия АКШ һәм Европаның көчле басымы астында: санкцияләр бугаздан тоткан, хәрби конфликт куркынычы зур. Болар барысы да бездәге халыкның социаль хәленә зур йогынты ясый. Әмма әлегә Мәскәү кыенлыклар урманы эченнән уңышлы гына бара кебек. Көнбатыш блок белән сөйләшүләр өстәле әзер инде. Путин яңа гына матбугат конференциясендә күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү буенча чиновникларга әмерләр бирде, казах тәҗрибәсен дә, мөгаен, искә алгандыр.

Бездә әлегә «омикрон» штаммы социаль һава торышын билгеләргә җыена кебек. Көнбатышта инде чир мәйдан тота. Израильдән коронавирус җиде чакрымлы адымнар белән һөҗүм итә дигән рәсми хәбәр алынды. Шимбә көнне иртән анда 17 мең 521 кешедә чир ачыкладылар. Халык саны ягыннан Татарстаннан ике тапкыр тирәсе генә зуррак булган төбәк өчен котчыккыч саннар бу. Күрәбез, «омикрон»га вакциналар да, тыюлар да чик түгел.

«Российская газета»ның дүшәмбе саны бездә дә инфекциянең Европадагы кебек шартлаулы рәвештә таралуы көтелүен хәбәр иткән язма бирде. Түбән Новгородта һәм Петербургта чит илләргә чыгып йөрмәгән кешеләрдә күпләп «омикрон» табылды инде. Димәк, чир «үзебезнеке»нә әйләнеп килә. АКШта бер көнгә 600–700 мең кеше, Италия кебек кечерәк илдә 200 мең кеше чирләвен исәпкә алсак, пандемиянең бездәге адымнары ничегрәк булачагын чамаларга мөмкин. Бер нәрсә өметләндерә: чир күпчелек очракта җиңел уза. Әмма берән-сәрән үлем очраклары да бар. Израильдә, мәсәлән, бер авыруда ул йөрәк чире – миокардит китереп чыгарды. Әмма миокардит, гадәттә, вакцинаның начар тәэсире буларак та күзәтелә, шуңа күрә гыйбри пациентының хәлен кайсы начарайтканын төгәл белеп булмый.

Россия табибы Анча Баранова «омикрон» давылының кискен булып, әмма тиз узып китәсенә өметләнә (Африка һәм Латин Америкасында ул шулай), вәләкин Россиянең географик үзенчәлекләре темпның акрынрак булуына да китерүе ихтимал дип әйтә. Бердәнбер саклану чарасы – социаль активлыкны киметү. Әмма алдагы тәҗрибә күрсәтә: дулкыннан читтә калу мөмкин түгел диярлек.

Пандемия хәзер грипп эпидемиясен хәтерләтә. Илкүләм берничә йөз мең кешенең берьюлы ятакка авуы элекке елларда була торган хәл иде. Ковид-19 белән саубуллашу аккорды булса иде инде бу соңгы өянәк.

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысасында тәүге чара. Болгарда узган Россия мөселманнары җыены тарихка әнә шулай кереп калды. Дүрт көнлек форумда Татарстан, Башкортстан, Мари Иле республикаларыннан, Мәскәү, Ленинград һәм Свердловск өлкәләре, Кузбасс һәм башка төбәкләрдән дин әһелләре катнашты.

Хәтерләсәгез, 2019 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Советына Юлламасында 1100 еллыкка багышланган тантаналы чаралар үткәрүгә әзерлек буенча йөкләмә биргән иде. «Әлеге вакыйга татар халкын үстерүдә, Россиянең әйдәп баручы диннәренең берсе буларак исламны торгызуда зур роль уйнады», – дип билгеләп үтте ул чакта республика җитәкчесе. Президент Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулуга әзерлек һәм аны бәйрәм итү буенча республикакүләм оештыру комитетын да җитәкли. 12 гыйнварда әлеге комитетның беренче утырышын уздырачак.

Болгарда узган форумда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Рөстәм Миңнехановның Җиддәдә узган «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышында Казанга «Беренче басма Коръән шәһәре» статусын бирү тәкъдиме белән чыгуын, вакцина ясаткан мөселманнарны 2022 елда хаҗ кылырга кертүне сорап, Согуд Гарәбстаны хакимиятенә мөрәҗәгать итүен дә искә алды.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарихи вакыйга уңаеннан бик күп чаралар оештырачак. Шуларның иң зуры – кулъязма Коръән. «Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан тагын бер зур проект башлыйбыз. Без, иң яхшы каллиграфларны җәлеп итеп, Коръәнне кулдан күчереп язарга җыенабыз», – диде мөфти. Моннан тыш ел дәвамында «Казан басмасы»н чыгару, рус телендә онлайн мәдрәсәне, кулъязма Коръән Мөсхәфен, «Даруль-кутуб» электрон китапханәсен, «Ибне Фадлан» документаль-нәфис фильмын тәкъдим итү дә күздә тотыла.

Форумда катнашучылар, беренчеләрдән булып, татар батыры образы белән дә танышты. Бу образны яңа сюжетларда, компьютер уеннарында, комиксларда, мобиль квестларда, мультфильмнарда кулланырга җыеналар. Якын киләчәктә «Туган батыр риваятьләре» дип аталган әкиятләр китабы да чыгачак. Бу җаваплы эш Татарстанның халык язучысы, драматург Зөлфәт Хәкимгә тапшырылган.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм актив иҗтимагый хезмәте өчен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Вәлиев** Разил Исмәгыйль улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

«Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Гайзуллина** Альбина Шамил кызына; «Татарстан Республикасының Алман йорты» автоном коммерциячел булмаган оешмасы музыканты, артисты **Илюшкина** Анастасия Валериевнага; «Барс-Рекордс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте вокалчы артисты (солисты) **Хәкимова** Алинә Васил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

БАЛАЛАРНЫ ДА АЯМЫЙ

ТАТАРСТАНДА 12–17 ЯШЬЛЕКЛӘР ӨЧЕН ВАКЦИНА КАЙТУЫН КӨТӘЛӘР

COVID-19

Мөрәҗәгать бар, көтәләр. Татарстанда коронавируска каршы балалар өчен вакцинаны кабул итәргә әзерләнәләр. «Спутник М» дип аталган вакцина ике компонентлы прививка санала һәм ул 12–17 яшьлек балалар өчен булачак. Әлегә аның турында нәрсә билгеле?

«Татар-информ»

Аерма хәрефтә генәме?

Балигъ булмаган балалар өчен коронавируска каршы «Спутник М» (башкача – «Гам-КОВИД-Вак М». – **Ред.**) вакцинасы узган елда теркәлде. Вакцина биотехнологик алым белән барлыкка килгән, ул тулысынча «Спутник V» составын кабатлый. Әмма балалар өчен вакцинада зәгыйфьләндерелгән вирус күләме биш тапкыр киметелгән. Билгеле инде: бала организмы белән олыларныкы бер түгел, балаларның иммун системасы вакцинага карата активрак җавап бирергә сәләтле. «Спутник М» вакцинасын сынаулар аның 93 процентка нәтиҗәле булуын күрсәткән. Гади генә әйткәндә, ун үсмернең тугызында коронавируска каршы антитәнчекләр пәйда булуы ачыкланган.

Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы хәбәренә караганда, Федераль закон нигезендә 12–15 яшьлек үсмерләргә вакцина ясату фәкать ата-ана яисә башка законлы вәкиле ризалыгы белән генә башкарылачак.

Гыйнвар башында узган матбугат очрашуында Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов республика исеменнән федераль министрлыкка гариза тапшырылганы турында хәбәр иткән иде. Аның сүзләренчә, республиканың балалар сырхауханәләре вакцина кабул итәргә тулысынча әзер, аларны кайтартылу белән куллана башлаячаклар.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат хезмәтенә вакцинага бәйле сорауны юлладык. Аларның җавабыннан аңлашылганча, әлегә вакцинага кагылышлы төгәл мәгълүмат юк. «Үзебез дә көтәбез», – диләр. Табиблар да җавап бирергә ашыкмый. Әле кулга тотып та карамаган дару турында нәтиҗә ясарга иртәрәк шул.

Дөньякүләм статистикага карасаң, балалар арасында коронавирус белән чирләп үлүчеләр күрсәткече 0,005 процентны тәшкил итә. 1 миллион авыруга 50 үлгән бала дигән сүз бу. Шулай да белгечләр чирнең балаларга да хәзер ешрак йогуын әйтә. Габричевский исемендәге Мәскәү эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү институтының клиник эшләр буенча директор урынбасары Татьяна Руженцова белдергәнчә, балаларда коронавируска каршы иммунитет дәрәҗәсе бик түбән. «Бу төркемгә караган, вакцина ясатмаганнар арасында инфекциянең тиз таралуына китерә. Авыру катлаулы уза», – дигән ул.

Чикләүләр гамәлдә кала

Эпидемиологик вазгыятьнең тотрыклы булуына карамастан, республика күләмендәге чикләү чаралары гамәлдә калачак. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган киңәшмә барышында Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин белдерде. Аның сүзләренчә, коронавируска каршы чаралар үтәлешен тикшерү буенча рейдлар үткәрү эшен дәвам иттерергә кирәк.

– Вазгыять үзгәрергә дә мөмкин. Шуңа күрә элеккечә эшләргә тиешбез, – диде Алексей Песошин.

Сүз уңаеннан, Татарстанда 2296351 кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан. 1863587се прививканың икенче дозасын алган. Кабат вакцина ясатучылар саны – 139822 кеше.

Олег МОРОЗОВ,
Россия Дәүләт Думасы депутаты:

„ Коронавирус җәмгыятьне тарката, минемчә, бу вирус аркасында кешеләрнең куркуы шулкадәр көчле, хәтта күктән мифик дошманнар тарафыннан нидер сиптерәләр дигән фикерләргә кадәр барып җитәләр. Элек мондый кешеләрне без акылдан язганнар дип санар идек, ә бүген алар модада, алар җәмгыятьнең бер өлешен үзләре артыннан алып бара. Бу – бераз гына үзгә вакыт өчен хас күренеш, җай чыгу белән Кашпировский, Чумак тарафдарлары һәм Җир яссы дип уйлаучылар пәйда була. Кешенең психикасы шулай корылган, күрәсең.

Кыш озын, җәй кыска булыр

Ел башыннан кар да ишеп яуды, бураны да дулап алды. Әле тагын салкыннар булырмы? Язны кайчан көтәргә? Балтач районының Яңгул авылында гомер итүче, газетабызның даими синоптигы Әмир Шәрәфиевтән әнә шул хакта сораштык.

– 2010 елда корылык булгач, ел фасылларының рәте киткән иде, – дип башлады ул сүзен. – Кыш уртасында кар яуды, җәен салкын булды. Ел фасылларын «дөресләр» өчен 10–11 ел кирәк, диләр. Шулай булып чыкты да. 2021 елда ел фасыллары һәммәсе үз урынында булды.

Әмир абыйның бер борчуы бар – элек аның сынамышлары туры килсә, соңгы елларда алар да сыната икән. Әйтик, 2020 елның декабре 2021 елның июнь аена туры килмәгән. Узган ел явым-төшем күп булырга тиеш иде, ди ул.

Әмма синоптик ел елга охшамый дигән фикердә. Ул ел фасылларының үз урынында килүен дә 33 елдан 33 елга табигатьнең кабатлануы дип аңлата. Баксаң, аның әйтүенчә, 11 елдан 11 елга һава торышында охшаш яклар күзәтелә икән. Алты ел ярымнан алты ел ярымга кышка охшап – җәй, җәйгә охшап кыш килүе дә чиратлаша, ди ул.

– Быел агачлар сарысын чыгару иртәрәк булды. Шуннан соң салкыннар булырга тиеш иде. Гадәттә, ул суыклар Раштуага туры килсә, быел ике көн алданрак күзәтелде. Әлегә салкыннар озакка сузылмый. Аннары берике көн җылытып җибәрә. Тиздән православларның Кач ману бәйрәменә суытачак. Шуннан соң салкыннар башланачак. Февральнең 7сендә хут суыгы булачак. Ул салкыннар 19–20 мартка кадәр сакланачак, – ди ул.

Әмир абый узган ел җәйнең бик озын булганлыгын да искә төшерде. Җәйнең майда ук килүенә шаккаткан идем, ди.

– Хәтерләсәгез, ул вакытта гөлҗимешләргә кадәр чәчәк атты. 9 майдан җылы көннәр торды. Әмма быел яз иртә килмәячәк. Ул бераз соңга калыр. Шулай булгач, җәй дә кыскарачак, – ди ул. – Узган елгы кебек корылык булыр дип уйламыйм. Быел яңгыр да вакытында явачак, эссе көннәр дә булачак.

КФУның атмосфера метеорологиясе, климатология һәм экология кафедрасы мөдире, профессор Юрий Переведенцев та, 19 гыйнварда Кач ману суыклары көтелә, ди.

– Һава торышын алдан фаразлап булмый. Сынамышларның бары тик 70 проценты гына туры килүен онытмыйк, – ди ул. – Гыйнвар аенда көчле салкыннар булыр дип уйламыйм. Ай ахырына кадәр һава температурасы нормадан нибары ярты градуска түбән булачак. Явым-төшем дә тиешенчә булыр дип көтелә. Гыйнвар аенда Татарстанда уртача айлык температура 13 градус салкын булачак.

P.S. Ел башыннан бирле Казанда айлык норманың 73 проценты күләмендә кар яуган. Башкаладан 294 мең тонна кар чыгарганнар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БӘРӘҢГЕ КҮБРӘК БУЛАЧАК

Яшелчә бәяләрен тотрыклы итү максатыннан, быел Татарстанда аларны үстерү мәйданнарын арттырырга планлаштыралар. Бу хакта республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров хәбәр итте.

Аның сүзләре буенча, узган ел республикада 5,9 мең гектар мәйданда 82 хуҗалык бәрәңге һәм башка төр яшелчә утырткан булган. Чәчү мәйданнарының 70 проценты алты районда урнашкан.

– Бәяләрне тотрыклы итү максатыннан, быел әлеге культуралар үсү мәйданнарын 12 процентка арттыру планы бар. Яшелчә үстерүче барлык җитештерүчеләргә гектарына 25 мең сум ярдәм биреләчәк. Ә мәйданны узган ел белән чагыштырганда 10 һәм аннан да күбрәк процентка арттырган хуҗалыклар һәр гектарга 40 мең сум күләмендә субсидия алачак. (Мәгълүм булганча, 2021 елда мондый ярдәм гектарына 25 мең сум иде. – **«ВТ».**) Актаныш, Арча, Әлмәт, Биектау, Алабуга, Чүпрәле, Балык Бистәсе, Сарман, Чирмешән, Чистай һәм Ютазы районнары җитештерү күләмен арттырырга ниятлиләр. Башка район башлыкларын да шуңа өндим, – диде Марат Җәббаров.

Ярдәм авыл хуҗалыгы кооперативларына һәм кулланучылар җәмгыятьләренә дә булачак. Шуңа күрә министр район башлыкларыннан халыктан бәрәңге һәм башка төр яшелчәләр җыюны оештыруны да үтенде.

Чыннан да, узган җәй коры килү сәбәпле, яшелчә һәм бәрәңге уңышы куандырырлык булмады. Аеруча «икенче икмәк»кә ихтыяҗ зур иде. Бу декабрь ахырына кадәр барган ярминкәләрдә бигрәк тә нык сизелде. Беренче көннәрдә халык, бәрәңге җитмәгәнлектән, шактый гына шау-шу да кузгатты. Шуннан соң министрлык яшелчә күләмен бермә-бер арттырды. Ягъни ярминкәнең беренче көннәрендә 140 тонна бәрәңге китерелгән булса, икенче атнада бу төркемдәге товарларны 412,5 тоннага кадәр арттырырга мәҗбүр булдылар. Шул исәптән бәрәңге – 270 тонна.

Министр үз чыгышында халыкны бәрәңге белән тәэмин итүче актив оешмаларны да телгә алды. Алар арасында «Татагролизинг» «Кырлай» агрофирмасы, «Бөреле» хуҗалыгы, Нәсим Дәүләтов, Минталип Миннеханов, Владимир Аппаков фермер хуҗалыклары, «Вятские Зори» җәмгыяте бар.

Гомумән алганда, узган ел ярминкәләр 23 көн оештырылды. Шуларның җидесе язын булса, калганнары – көз һәм кыш айларында. Халык товарларны Казанның – унбиш урынында, «Яңа Тура» һәм «Осиново» бистәләрендәге, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге мәйданнарда ала алды. Марат Җәббаров әйтүенчә, гомумән алганда 1,9 млрд сумлык продукция сатылган.

– Ярминкәдәге бәяләр, гадәттәгечә, арзанрак иде, – диде министр. – Яшелчә халыкка – 13–48 процентка, он – 25, карабодай – 20, атланмай һәм сыр – 30, йомырка һәм кош ите – 7, шикәр комы 10 процентка арзанрак бәядән тәкъдим ителде.

Узган ел Россиядә көнбагыш уңышы да начар булды. Шул сәбәпле, көнбагыш маена да бәяләр күтәрелде. Татарстанда көнбагыш мае җитештерү, 2020 ел белән чагыштырганда, 20 процентка кимегән. Марат Җәббаров шулай ук шикәр комына бәя артуны да искә төшерде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

kzn.ru

ЯРМИНКӘДӘ НӘРСӘ КҮПМЕ САТЫЛГАН

Барлык төрдәге ит – 2,6 мең тонна
Сөт – 330 тонна
Шикәр комы – 1,3 мең тонна
Он – 750 тонна
Ярмалар – 300 тоннадан артык
Йомырка – 4 млн данә
Бәрәңге – 6 мең тонна
Яшелчә – 5 мең тонна
Ашлык – 3,3 мең тонна

СИНЕҢ КЕБЕК КЕШЕ КИРӘК

Милләттәшләр

Нәкъ әкияттәге кебек килеп чыкты бу. Көннәрдән беркөнне Арча педучилищесында бергә укыган төркемдәшем Гөлсинә МӨБАРӘКШИНА Сургутка китте дә барды. Эшләргә дип. Пенсия яшенә җиткәч бит инде, шуңа күрә шикләнеп тә куйган идем. Сәбәбен дә сораштым. Нурлат районындагы туган авылы Бикколда башлангыч сыйныфларда укыта иде. Мәктәпне япканнар икән. Кыскартылуга эләккән.

Бар яктан килгән кыз иде Гөлсинә. Менә дигән укытучы да булгандыр дип уйлыйм. Яхшы укый, сәхнәдән төшеп тормый, оештыру сәләтенә дә ия, шул ук вакытта искиткеч гади, ярдәмчел иде ул. Юллама белән Аксубайга китеп озак тормадылар, педучилищеда ук яратышып йөргән Арча егете Илгиз белән кавыштылар да Гөлсинәнең туган авылында йорт җиткезделәр. Илгизнең генә гомере кыскарак булды. Озак та үтми, олы улы да гаиләсен калдырып китеп барды. Авыр көннәр кичерде сабакташым, мәктәп, балалар аның өчен зур юаныч иде. Бу юлы да Сургут турында гына сөйләшербез дигән идек, хатирәләрне тагын бер кат барларга туры килде.

«Әле ярый тәвәккәлләдем»

– 2010 ел иде бу. Матур гына укытып йөри идек әле. Эшсез калгач, аптырап киттем. Көч-куәт ташып тора кебек, балаларга да бик күнеккәнмен. Пенсиягә генә яшәү һич кенә дә мөмкин түгеллеген дә аңлыйм. Тормышны ялгызым тартам. Җитмәсә, кредитларым да бар. Акча эшләү ниятеннән 2018 елга кадәр кем генә булмадым мин: сатучы да, диспетчер да, администратор да… Хәтта буровойда пешекче булырга да туры килде. Шунысын аңладым: һәр эш үзенчә кызыклы икән. Барысын да яратып башкардым. Тора-бара, гомер буена укытучы булып эшләп, тирә-юнемдә ниләр булып ятканын аңлап бетермәгәнмен, дигән фикергә дә килдем әле.

Бервакыт мин эшләгән кунакханә бик озакка капиталь ремонтка ябылды. Шулай итеп, чираттагы тапкыр эшсез калдым. Инде нишләргә дип аптырап йөргәндә, авылдашым Гүзәл Шәрәфетдинова Сургуттан ял итәргә кайтты. Ул күптән гаиләсе белән шунда яши инде. Мәктәптә дә укыта, якшәмбе мәктәбенә дә йөри икән. «Сургут шәһәренең татар үзәгенә синең кебек кеше кирәк, Гөлсинә апа», – дигәч, кызып киттем. Дөрес, гомер буе авылда яшәгәч, мондый адымга бик зур тәвәккәллек кирәк. Әле ярый булдырганмын дип, хәзер сөенеп бетә алмыйм.

«Бер күрүдә яраттым»

Ике тәүлек поездда тирбәлгәннән соң килеп төштем мин Сургутка. Ул вакытта ниләр кичергәннәремне үзем генә беләм. Шәһәрдә яшәп караган кеше дә түгел бит әле мин. Әле ярый каршы алдылар. Вокзалдан гына кире кайтып китүем дә бар иде. Бераз ял иткәч, шул көнне үк шәһәр күрсәтергә алып чыгып киттеләр. Дөрес эшләгәннәр икән. Сургутны беренче көннән үк яраттым. Көзнең бик матур, кояшлы көне иде ул. Урамнар чиста, киң. Шәһәр тайга уртасында салынган бит. Ул яшәр өчен шундый уңайлы итеп төзелгән. Урыны-урыны белән урман калдырылган, анда ял итәргә сукмаклар, парклар булдырылган.

Татарлар

Төп эшем – татар үзәге бит әле. Төне буе йоклый алмый очрашу турында уйланып яттым. Ничек кабул итәрләр? Эшләп китә алырмынмы? Бу бит сиңа һәр почмагы таныш Биккол авылы да, хәтта Нурлат районы, Татарстан да түгел. Анда барыбер үзеңнекеләр. Тик юкка кайгырып ятканмын икән. Сургутта яшәүче татарлар мине зур өметләр баглап, күптән көткән кунак кебек каршы алдылар. Татар теленә мөнәсәбәтләрен күрсәң тагын! Юкка гына, чит җирләрдә яшәүче татарлар телне ныграк саклый, дип әйтмиләр икән. Кыскасы, мин бөтенләй башка дөньяга килеп эләктем. Кайберләре телне онытып бетерә язган, балалары, оныклары белсен иде дип тырышалар. Икешәр-өчәр бала җитәкләп, якшәмбе мәктәбенә һәр ял саен бәйрәмгә килгән кебек җыелалар. Йөзләрендә нур балкый. Югыйсә атна буе салкында эшләгәннәр бит инде. Диванга сузылып ятып, ял итеп алсалар да сүз әйтә алмыйсың.

Сургутта татар мәктәбе 30 еллап эшләп килә икән инде. Башта ул татар-башкорт мәктәбе дип аталган. Тора-бара татарныкы гына булып калган. Оешмабыз да Сургут шәһәре татар милли автономиясе дип атала. Җитәкчесе – Ханты-Манси округының атказанган коммуналь хуҗалык хезмәткәре, Самара егете Рафаил Ульбеков. Сургут шәһәрендә 100дән артык милләт яши. Татарлар, руслар һәм украиннардан кала, өченче урында. Шәһәрдә милләттәшләребезнең абруе бик зур. Күп кенә оешмалардагы җитәкче урыннарда да татарлар эшли. Кайберләре шәһәр тормышында аерым урын алып торалар. Бертуган Фазыл һәм Миндар Әгъләмовларны, мәсәлән, Сургутта белмәгән кеше юк. Алар запчастьлар сату буенча кибетләр челтәрен җитәкли. Чыгышлары белән Чирмешән районының Әмир авылыннан. Авылдашларына да ярдәм итәләр. Авылда калган яшь парларга өй салырга булышалар, яңа туган балаларга акчалата ярдәм күрсәтәләр. Монда да талантларны үстерүгә, бәйрәмнәр оештырырга, милләтне саклап калырга күп көч куялар. Күренекле татарлардан педагогия фәннәре докторы, профессор Рафис Шәймәрдановны да атап китми мөмкин түгел. Зәй районының кечкенә генә авылында туып-үскән галим – Сургут дәүләт педагогия университетында өлкән фәнни хезмәткәр, югары хөкүмәт бүләкләренә ия. Милләттәшебез Радик Шәяхмәтов – табиб, шәһәрнең үзәк хастаханәсендә травматология бүлеген җитәкли. Эшем катлаулы дип тормый, милли оешма советы әгъзасы буларак, барлык чараларны үткәрүдә катнаша. Шунысы игътибарга лаек: ул Татарстаннан читтә туып үскән, татар телен үзлегеннән өйрәнгән, хәзер исә Дәрдмәнд шигырьләрен күңелгә үткәрерлек итеп сөйли. Альбина белән Илдар Фәттаховлар милләттәшләрен һәр атна чәй куеп каршы алсалар, Әлфия апа Нурисламова өч оныгын мәктәпкә – татар телен, мәчеткә догалар өйрәнергә йөртә.

Мәктәптә дәресләрне, ата-аналар белән киңәшләшеп, үзебез төзегән план нигезендә оештырабыз. Ул аралашу теле, милли гореф-гадәтләрне өйрәнү, татарның күренекле шәхесләрен барлау юнәлешендә төзелгән. Күп кенә темаларны җырлар аша бирергә тырышабыз. Һәр баланың үз папкасы бар. Анда иҗади эшләр тупланып бара. Округның башка шәһәрләрендә дә милли оешмалар эшләп килә. Үзара фикер алышып, бик тату яшибез. Видеоматериаллар интернетка урнаштырылгач, башка төбәкләрнең татар оешмалары белән аралашырга да җай чыгып тора.

«Сагынырмын инде…»

Сургутта яшәүче татарларның күбесе Татарстаннан һәм Башкортстаннан килеп урнашкан. Яшерен-батырын түгел, күбесе туган җирләреннән акча эшләү максатыннан кузгалган. Шунысын гына әйтә алам, Сургутта ялкау кешеләр эшли алмый. Ә эш яраткан кешеләргә мөмкинлек зур. Читкә акча эшләргә чыгып китү – баштарак вакытлыча яшәү урыны кебек тоела ул. Һәрберсе туган җирен сагынып яши. Өлкәнәйгән көндә кайтырга дип, туган җирендә яшәр урын әзерләп кую белән мәшгульләр. Тик, пенсиягә чыгып, туган илгә киткәннәр дә Сургут белән араны өзә алмый, чөнки монда пенсиядәгеләргә шактый ташлама каралган. Гомер итә-итә туганнарга әверелгән дуслар белән дә араны өзеп бетереп булмый.

Мин үзем дә туган якка кайтып китү уе белән яшим. Җәй җиткәч, сагынып, авылыма кайтам. Көз башлангач, ашкынып, Сургутка киләм. Кайчан булса да, бөтенләйгә кайтып китәргә кирәк булачагын күз алдыма китерәм дә, чыннан да, авыр булып китә. Күпме дусларым, укучыларым кала бит монда! Ата-аналарның үтенече буенча мәктәптә дә башлангыч сыйныфларны укытып йөрим бит әле. Соңгы вакытларда читтә яшәгән татарлар турында еш уйланам. Элегрәк туган җирдән читтә ничек яшиләр икән, авырдыр инде дип гаҗәпләнә идем. Хәзер инде язмышлар йөрткәнен аңлыйм. Кайда гына яшәсә дә, татарның ныклыгы, үз сүзен әйтә белүе белән горурланам. Туган йортыбыз Татарстан белән элемтәләр генә өзелә күрмәсен иде дигән теләктә калам. Монысы барыбыз өчен дә бик кирәк. Шул вакытта гына без бөтенлегебезне югалтмабыз.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ХӘМИДУЛЛИН ФИЛЗӘ ГАРИФ УЛЫ

(03.01.1936 – 05.01.2022)

Татарстан Републикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, элекке ТАССР Премьер-министры урынбасары –Икътисад һәм фаразлау буенча дәүләт комитеты рәисе Хәмидуллин Филзә Гариф улы 5 гыйнвар көнне 87 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Филзә Хәмидуллин 1936 елның 3 гыйнварында Казанда туа. Хезмәт эшчәнлеген 1958 елда Казан финанс-икътисад институтын тәмамлаганнан соң ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты инструкторы вазыйфасында башлап җибәрә. Шуннан соң Казан финанс-икътисад институтына мөгаллимлек эшенә күчә, өлкән укытучы, доцент, кафедра мөдире, 1980 елдан – Казан финанс-икътисад институты ректоры була.

Филзә Гариф улы 1990 елда ТАССР Министрлар Советы Рәисе урынбасары, 1991 елда – ТАССР Премьер-министры урынбасары – ТАССР Икътисад һәм фаразлау буенча дәүләт комитеты рәисе итеп билгеләнде. 1995–2003 елларда Татарстан Республикасы Президенты каршында Социаль-икътисади мәсьәләләр буенча дәүләт киңәшчесе булды. 2003–2005 елларда Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе Федераль Җыены Федерация Советында хезмәт куйды.

2006 елдан – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Икътисади сәясәт һәм төбәкнең өстенлекле программаларын тормышка ашыру мәсьәләләре комиссиясе рәисе булып торды.

Яңа базар мөнәсәбәтләре булдырылган чорда Филзә Хәмидуллинның турыдан-туры катнашында Татарстан Республикасы икътисадында зур структур үзгәрешләр хәл ителде, республиканың сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы өлкәләрендәге мөмкинлекләрен саклап калуга ирешелде, халыкның аз керемле катлауларына социаль ярдәм итүнең махсус адреслы системасы эшләнде.

Филзә Гариф улы – Татарстан Республикасының социаль-икътисади яктан инновацион, югары технологияле үсешен һәрвакыт эзлекле төстә яклап-хуплап килгән шәхес. Ул Татарстан Республикасы Дәүләт икътисади һәм социаль алгарыш программасының төп авторларыннан берсе булып торды. Аның фәнни тикшеренүләре һәм программалары 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Социаль-икътисади үсеш стратегиясе нигезен формалаштыруга хезмәт итте.

Филзә Хәмидуллин икътисад фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (академик) булды. Аның катнашында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары өчен алтмыштан артыграк фәнни-гамәли тәкъдимнәр эшләнде, халыкара, Россия, республика күләмендәге әһәмиятле фәнни-гамәли конференцияләр оештырылды.

Филзә Гариф улының күп еллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың социаль-икътисади үсешенә керткән өлеше югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденнары, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре, «ТАССРның атказанган икътисадчысы» мактаулы исеме, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы.

Филзә Хәмидуллинның тормыш юлы зур ихтирам-хөрмәткә лаек. Кайда гына эшләмәсен, ул үзен югары дәрәҗәдәге профессионал, зирәк, көч-куәте ташып торган, үз эшенә тугрылыклы кеше һәм ватанпәрвәр буларак танытты.

Филзә Гариф улы Хәмидуллинның – уникаль язмышка ия булган гүзәл шәхеснең һәм талантлы җитәкченең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. Миңнеханов, М.Ш. Шәймиев, Ф.Х. Мөхәммәтшин,
А.В. Песошин, Ә.Ә. Сәфәров, М.Р. Шаһиәхмәтов,
И.Р. Метшин, М.Х. Сәлахов, Д.А. Таюрский

«ЯЛГЫШЛАР»НЫ ТӨЗӘТӘ-ТӨЗӘТӘ…

Балык Бистәсе районы әдәбиятыбызга күп талантлы каләм ияләрен бирде. Бүген укучыларга, күркәм юбилее уңаеннан, шуларның берсе – балачагы һәм яшьлеге Иске Арыш авылында узган, егермегә якын китап авторы, язучы Әхәт САФИУЛЛИН белән әңгәмә тәкъдим итәбез.

:: Әхәт абый, сезнең тормышта гаҗәпләндерә торган хәлләр күп. Хәтта туган җирегездән үк башлап…

– Туган җиремә килсәк, мине гомер буе озата килгән «ялгыш»ларымның беренчесе ул: дөньяга әби-бабамнар гомер иткән авылда аваз саласы урында, Донбасста туганмын. Яшәү дәверендә мин аларны гел төзәтә килдем. Беренчесен дә: тууыма сигез ай тулгач, әти-әниемнең кулларыннан тоттым да: «Йөрмәгез монда күмер тузанын иснәп, сезнең бәхет – авылда!» – дип, җилтерәтеп, шунда алып кайтып киттем. Борынгыларның «Хәрәкәттә – бәрәкәт» дигән сүзен истә тоткан хәрәкәтем шул Донбасс – Балык Бистәсе юлыннан башланды. Шуннан бирле, «ялгыш»ларымны төзәтә-төзәтә, хәрәкәттә мин. Башлангыч мәктәптән соң җидееллык мәктәпле Балыклы Чүкәй юлын таптадым. Чөнки тора-бара анда да, авылыбыз Иске Арышта да ачылачак урта мәктәпләрне көтеп тормыйча туып ялгышканмын…

:: Сез юмор күзлегеннән караган ул «ялгыш»лар шуның белән беткәндер?

– Киресенчә, яңалары башланды. Урта мәктәптән соң, киләчәктә әдәбиятка алып керергә тиешле вузга барасы урынга (шигырьләр яза идем!), Казан авыл хуҗалыгы институты ишеген ачып кердем. Мөгаен, балачагын сугыш еллары урлаган, алты-җиде яшьтән әнинең кул арасына кереп, тормыш авырлыкларын кичергән «егет» буларак, киләчәктә авыл яшәешен җиңеләйтү теләге булгандыр (әллә чираттагы ялгышыммы?), механизация факультетына кермәкче идем. Тик рус теле буенча язма имтиханнан «икеле» алдым…

Шуннан тезелеп китте инде ул ялгышлар… Башта, сатирик Хазанов әйтмешли, «калинария» училищесы ишеген шакыдым. (Моны ничек ялгыш димисең?!) Аны төзәтергә «Яшь сталинчы» («Татарстан яшьләре») газетасында эшләгән, аннары язучы булачак Мәгъсүм Хуҗин ярдәм итте. Мәктәптә укыганда бу газетага язгалый идем. Бер мәртәбә ул, укырга кая керүем белән кызыксынып, «калинария» икәнен белгәч, катгый итеп: «Ал аннан документларыңны, ир-атлар һөнәрен сайла!» – дип кырт кисте. Шуннан соң ике ел техник училищеда төзелеш эшен өйрәндем. Бу газетада әдәби түгәрәккә йөрдем. Соңыннан Татарстанның мәгариф министры булып эшләгән профессор, ул чакта, минем кебек, газетага язгалап торган керәшен егете Володя Иванов белән күләмле язмалар әзерләвебез истә калган. Ул министр чагында янына кергәнем бар (ул чорда һәр түрә янына кереп була иде). Эше турында сорашкач, уйга калып: «Өстә дүрт мең мәктәп бит, малай!..» – дип көрсенгән иде. Чиста күңелле кеше иде…

:: Иҗатыгыз шигырьләр язудан башланган, Әхәт абый. Алай да 2002 елда чыккан «Туган якның таң җилләре» дигән китабыгыз – бердәнбер шигъри җыентык. Димәк, инде шигырьләр язмадыгыз?

– Шигырь – күңел халәте җимеше. Үземне шагыйрь дип санамыйм. Сафьян Ибраһимов, Фәрит Хатыйпов, Рамил Курамшин кебек талантлар кайбер шигырьләремә көйләр язды. «Балык Бистәсе таңы» дигәненә көй язган Сафьян һәм аны җырлаган Габдулла Рәхимкулов белән дуслашып та киттек. Алар Язучылар берлегендә узган 60 яшьлек юбилеемда да катнаштылар. Габдулла абый авырып торган килеш килде һәм берничә җыр җырлады. Тик бу аның соңгы чыгышы булды: икенче көнне үлүе турында авыр хәбәр килде… 2001 елда, аңа багышлап, «Моңлы җыр булып…» дигән истәлекләр җыентыгы әзерләп чыгардым.

Күңел халәте таләп иткәндә, хәзер дә языла шигырьләр. Тик яңа җыентык итеп чыгарырга җыенмыйм – басарга әзерләп куелган проза әсәрләрем дә чират көтеп ята… Ә миңа, хатын дөрес әйтсә, инде 85 яшь тула икән…

:: Кайчан прозага күчтегез соң, Әхәт абый? Беренче хикәя кайчан язылды?

– «Аерылышканда кавышу» дигән беренче хикәямне 1956 елда, техник училищеда укыганда яздым. Һәм тоттым да (булган бит кыю чаклар!) аны «Социалистик Татарстан» газетасына бирдем. Аны язучы Сафа Сабиров, фәлән көнне килерсең, дип алып калды. Килдем, ни әйтер, дип калтырап утырам. «Укып чыктым, хикәяң ошады», – диде ул. (Иркен сулап куйдым.) Аннары: «Тик… – дип дәвам итәргә җыенды. (Утырган җиремнән каядыр төшеп киткәндәй булдым.) – Тик темасы буенча безнең газетага бармый». Әйдәле, диде дә «Яшь сталинчы»га төштек (ул чорда редакцияләр Бауман урамындагы 19 нчы йортта иде). «Сезгә яхшы хикәя алып килдем. Үзем укып чыктым. Менә авторы», – диде ул анда, мине күрсәтеп. «Яхшы, Сафа абзый, сез хуплаган икән, басарбыз», – диделәр аңа. Ул хикәя ике санда басылып чыкты.

Тагын да канатланып язарга керештем, тик никтер (йөрергә вакытым булмадымы, әллә кыюсызлык бастымы) аларны редакцияләргә шактый соң гына бирә башладым. 1980 елда «Казан утлары»нда төзүчеләр турында язылган «Гел зәңгәр булмый күкләр» дигән күләмле хикәям фотом белән басылды. Аны Төзүчеләр көнендә радиодан тапшыралар иде. Шуннан буылып торган буа ерылды. Әйберләрем татар басмаларында еш басыла башлады. 1982 елда хикәяләр һәм берәр повесть кергән «Язларында ялгыз йөрсәң…», 1986 елда «Онытылган вәгъдә» дигән китапларым дөнья күрде. Иҗат юлымда, Сафа абыйдан башлап, гел яхшы кешеләр очрап торды.

:: Инде ике китап авторы була торып, нигә Язучылар берлегенә 1991 елда гына алындыгыз? Ул китапларның сатира һәм юморга бернинди катнашы булмаса да, Балык Бистәсендә узган 70 яшьлек юбилеегыз язучы-сатирик буларак үтте кебек. Болары да гаҗәпләндерә бит…

– Кайчак аңлап булмаган сәбәпләр дә була икән. Мин Союзга (ул чакта шулай йөртелде) нигә шулай соң алынуымны үзем дә аңлый алмыйм. Барлас абый да: «Нигә Союзга кермисең инде син?!» – дип гаҗәпләнә иде. Беренчедән, мин эшләвемне һәм вакыт тигән чакларда язуымны белдем, анда керү турында уйламадым да. Ул тирәдә йөрергә вакытым да юк иде: төзүчеләр хәтта ял көннәрендә дә эштә. Аннары, инде гариза биргәч тә, аның каралмыйча озак ятуының сәбәбе, бәлки, «технарь» булуымдадыр дип тә уйлыйм.

Союзга кергәнче мин, 1980 елдан башлап, сатирик буларак шактый танылган идем: юмористик һәм сатирик хикәяләрем басылмаган басма юк иде! Аларны рус газета-журналлары да бик теләп бастырды, радиодан да күп яңгырадылар. Ә «Чаян»ның татарчасында да, русчасында да даими рәвештә чыгып килделәр, җыентыкларга кертелделәр… Алар бик күп җыелды, теге китаплар янына «Чаян» журналларын да өстәгәч, Аяз Гыйләҗев (кабул итү комиссиясенең җитәкчесе иде бугай), аларны кулына алып: «Күрегез бу галәмәт хезмәтне!» – диде. Шулай итеп, Союзга «тагын бер тапкыр» керерлек сатирик әсәрләр язган идем инде.

:: Бүгенге көн әдәбиятын ничек бәялисез: үсештәме ул, торгынлыктамы? Телебез киләчәген ничегрәк кузаллыйсыз? Хәзер газета-журналларның тиражы да борчу тудырырлык бит…

– Мин хәзерге көн әдәбиятын үсештә дип саныйм: күләмле роман, повестьлар да языла, сирәк вә аз тираж белән булса да, китапларыбыз да басыла. Әмма һәммәбезне алда ни булачагы борчый. Мәктәпләрдә телебез факультатив рәвештә өйрәнүгә генә кала икән, димәк, тора-бара татар укучыларыбыз да, вузларда телебезне укытырлык укытучыларыбыз да әзерләнмәячәк, ә туган телебездә язучы әдипләребез буыны китә барган саен, милли язучыларыбыз да, журналистларыбыз да калмаячак. Тик әле телебез берникадәр вакытка, әйтик, хәзерге һәм әле татар мәктәп-вузларында белем алган буын яшәгәндә, сакланыр. Ә аннары аны фаразлау да куркыныч. Әлбәттә, талантлар киләчәктә дә булыр, әсәрләр дә язылыр, тик инде алар татар телендә булмас… Әгәр киләчәктә Россиянең милли мәгарифкә карашы, сәясәте үзгәрми икән, безне хәзер мәчетләрдә, төрле үзәкләрдә ачыла торган татар телен өйрәнү курслары гына коткармаячак. Мин аларның ачылуын хуплыйм, алар телне саклауда роль уйнар. Тик әдәби тел булуын тәэмин итә алмаслар. Хәзер тел мәсьәләсе турында борчылып күп сөйлибез, язабыз. Бу аңлашыла да, чөнки тел беттеме, милләт тә юкка чыгачак дигән сүз. Матбугатта кайбер галимнәребез киләчәктә дәүләтчелегебез дә булачак дигән оптимистик фикерләр дә әйтә. Ничек? Кайчан? Нинди очракта? Җавап бирелми. Аларны укып: «Бирсен Ходай!» – дип куям. Кем белә, бәлки, безгә, чигенә-чигенә, бер яклы толерантлык күрсәтә-күрсәтә шушы көнгә калуыбызның зур ялгыш булуын исбатлап, шундый көн дә килер. Дөнья бик үзгәрүчән бит ул!

Әңгәмәдәш – Рамазан КӘБИРОВ

pixabay.com

Аяк өсте йоклап йөрмә,

ЯКИ ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМНӘРЕННӘН СОҢ НИЧЕК «УЯНЫРГА»?

Табын тулы ризык, сый вә хөрмәт, чиксез тоелган яллар, соң ятып, соң гына уянулар режимы... тәмам! Моңа ышану кыен булса да, чынбарлыкны кабул итүдән башка чара юк. Белгечләр исә гадәти режимга кайтуны йокыны көйләүдән башларга киңәш итә. Бу турыда тулырак КФУның Университет клиникасы табиб-сомнологы Лилия ШАҺИӘХМӘТОВА сөйләде.

Йокы режимы бозылуның зыяны нидә?

АКШның Боулдер университеты галимнәренең тикшерену нәтиҗәләренә ышансаң, йокы режимы бозылу организмда төрле функцияләр өчен җаваплы органик һәм органик булмаган 129 кушылмага, ягъни күзәнәкләргә зыян сала. Нәтиҗәдә кеше диабет, депрессия, гипертония һәм симерү кебек җитди авырулардан интегергә мөмкин. Моннан тыш, көчсезләнгән организмның вируслы инфекцияләргә һәм стресска каршы тору сәләте дә бик түбән дәрәҗәдә була.

Шулай ук галимнәр режим белән бергә гормональ фонның да бозылуын раслаган. Мәсәлән, иртәләрен организмны салмак кына уяту өчен җавап бирүче кортизол гормоны артыгы белән эшләп чыгарыла башлый. Төшкә кадәр йокласак та, яисә нибары бер сәгатькә артыграк йокласак та арып уяну, көн дәвамында хәлсезләнеп йөрүнең сәбәбе шунда инде.

Режимны ничек кайтарырга?

Лилия Шаһиәхмәтова да йокы һәм ял режимы сәламәт яшәү рәвешенең нигезен тәшкил итүен искәртте. «Озын Яңа ел яллары кешене иялләнгән режимыннан чыгара. Бу хәлне булдырмый калу мөмкин түгел диярлек, шулай да без бу ялларга да, озын ялլардан соңгы эш көннәренә дә алдан әзерләнә алабыз», – ди белгеч.

Быел инде кемдер алдан әзерләнергә соңга калгандыр. Шулай да табиб биргән киңәшләргә колак салу соң булмас. «Без Яңа елны мул өстәл, яхшы эмоцияләр, артык якты хис-кичерешләр, күңел ачулардан башка күз алдына китермибез кебек. Ләкин ялларда калориясе зур булган ризыкларны, тәм-томны җиңелрәк ризыкларга, мәсәлән, яшелчәләргә алыштырырга, шулай ук күбрәк чиста су эчәргә кирәк».

Шуннан соң иртә яту һәм иртә тору турында уйлый башларга була. Белгеч сүзләренчә, моның өчен көн дә бер вакытны сайларга кирәк. «Билгеле, безнең организмга үз режимына кайту өчен шактый вакыт кирәк булачак. Әгәр дә кеше көн саен 22.00 сәгатьтә йокыга китеп, 6.00 сәгатьтә уяна икән, организм да бу вакытка җайлаша. Бездән исә шушы тәртипне саклау гына таләп ителә. Хәтта ял көннәрендә дә».

Белгеч бүгенге эпидемиологик вазгыятьне дә исәпкә алырга киңәш итте. «Ял көннәрендә дә, эштән соң да саф һавада йөрергә кирәк. Иммунитетны ныгыту юлларын барлагыз. Кояшлы көннәрдә өйдә утырмагыз – хәзер безнең организмга D витаминының иң кирәк чагы», – диде ул. Моннан тыш, Лилия Шаһиәхмәтова көн дәвамында физик эш күбрәк булган саен, йокы сыйфатының яхшыруын да әйтте.

Табиблар әйтүенчә, иртән ятактан торуның да үз тәртибе бар. «Әгәр кисәк сикереп торсаң, көнең баш авырту, кан басымы төшү, арка һәм буыннар авырту белән башланырга мөмкин», – ди Лилия ханым.

Табиб-невролог Игорь Орлов, уянуга, яхшылап киерелеп, тартылып алырга киңәш итә. «Туры килеш яткан чакта гәүдәне кискен генә вертикаль хәлгә күчерү кан әйләнеше системасы өчен зыянлы. Бу баш әйләнү, кан басымы уйнауга китерергә мөмкин. Өлкән яшьтәге кешеләр өчен бу аеруча куркыныч. Кисәк торып, аңны югалтырга да була. Шуңа да йокыдан ашыкмый гына торырга кирәк», – дип аңлатты ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ (843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ӨЙЛӘНҮ ТҮГЕЛ СӨЙЛӘНҮ

НИЧЕК ИТЕП БИШ ХАТЫН-КЫЗ БУЛАЧАК ТОРМЫШ ИПТӘШЕН ТӨРМӘДӘН ЧЫГАРГАН?

Суд залыннан

Тикшерү органнары тарафыннан җинаять эше ачылып, эшләре Лаеш районы судына барып җиткән бу биш хатын-кызның язмышлары төрле булса да, булачак тормыш иптәше белән танышу тарихлары бер-берсен кабатлый.

Мөстәкыйль тормыш корып, балалар үстерү, бәхетле булу турында хыялланган хатын-кызлар гаделлек өчен көрәшеп, бәлагә тарыган бер ир-атка булышырга алына. Һәркайсы үз теләге белән кулдан килгәнчә бичара иргә ярдәм итмәкче. Гаепләнүченең суд барышында: «Акчаларын минем карточкага үз теләкләре белән күчерделәр», – дип аклануы да шуңа бәйле бугай.

pixabay.com

«Киләчәккә өметем уянды»

Тикшерү материалларыннан күренгәнчә, Казанда яшәүче 32 яшьлек Алик Данилов булачак корбаннарын танышулар сайты аша табып алган.

Әлеге сайтка махсус кереп карадым: кем белән һәм нинди максатларда танышырга теләвеңә карап, монда ир-атларның яки хатын-кызларның төрлесен табарга була. Бернинди документ та, тикшерү узасы да түгел. Бары тик исемеңне күрсәтеп, әлеге сайтта теркәлергә генә кирәк. Башкасын кәрәзле телефон аша ачыкларга кала.

Яшьрәк чакта парын табарга өлгерә алмый калган ир-ат яки хатын-кызлар әлеге сайт аша үз парын таба икән – аннан кемгә зыян? Ишетеп белүемчә, арада үз тиңнәрен табучылар да аз түгел. Ни дисәң дә, ялгыз яшәүгә караганда, парлы тормыш күңеллерәк. Мондый ыгы-зыгылы заманда интернет аша танышу да гөнаһ түгелдер. Тик нәтиҗәсе генә уңай булсын.

Казанның Кызыл Позиция урамында яшәүче Елена Романова да үзеннән ике яшькә олырак Алик Данилов белән танышулар сайтында аралашып китә. Көн саен эштән кайткач, озын-озаклап телефон аша хәбәрләшү ялгызлыктан арыган бу ике кешене көннән-көн күбрәк якынайткан булса кирәк. Елена моңарчы таныш булмаган ир-атның үзе турында үтә тыйнак итеп язуына игътибар итә, фотосына карап соклана. Үз чиратында шәхси тормышы, әти-әнисенең ничек итеп аны югары белемле итәргә тырышуы, әтисе вафатыннан соң, биш елдан артык авыру әнисен тәрбияләве турында яза.

Тормышта беркемнең дә күңеле буш түгел. Яңа танышының язмышы тагын да катлаулырак икән бит. Кайчандыр танылган спорт остасы, автосервис хуҗасы Алик Данилов хатыны һәм кызының гомере өзелүгә сәбәпче булган берәүне кыйнаган өчен төрмәдә утыра. Үзен вакытыннан элек иреккә чыгаруларын сорап, гариза да язган. Моның өчен тикшерү эшләрен яңабаштан карап, хөкем карарын үзгәртү зарур. Бу эшләр бушлай эшләнми, акча кирәк. «Синең белән танышканнан бирле, тормышка өметем уянды. Бергә-бергә бәхетле итеп яшисем килә», – дип күңел җылытырлык сүзләр язган эшмәкәр ир-ат иреккә чыгу белән бурычын кайтарачак, имеш.

Кыйммәткә төшкән «бәхет»

Тикшерү материалларыннан күренгәнчә, 2020 елның 21 июнендә Елена Романова Казанның Юлиус Фучик урамында урнашкан электрон терминалдан Алик Данилов күрсәткән номерга 35 мең сум акча җибәрә. «Бик зур рәхмәт. Эш башланып китте. Бурычымны чыгу белән кайтарачакмын», – дигән шатлыклы хәбәр ала.

Тик акча җибәрү хәлләре моның белән генә тукталып калмый. Бер атнадан ашыгыч рәвештә 60 мең сум кирәк була. Аннары Еленага Лаеш районының Державино бистәсендәге «МТС» кәрәзле телефон хезмәте аша 200 мең сум акча салырга туры килә.

Бәхетле булу өчен берни кызганыч түгел. Елена да әти-әнисеннән калган барлык акчаны шул максатка тота. Өченче тапкырында – 198 мең, тора-бара 331 мең сум акча җибәрә. Аннан тагын кирәк була. Шулай итеп, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә барлыгы 1 миллион 700 мең сум акча Алик Данилов әйткән карточка номерына җибәрелә. Тик нәтиҗәсе генә көткәнчә булып чыкмый. Төрмәдән чыгарга тиешле көннәрдә ир-ат хәбәрсез югала. Борчуга төшкән Елена, бар эшен ташлап, булачак ирен эзләргә тотына. Ахыр чиктә хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Менә шунда инде сәер хәлләр ачыклана башлый. Аның кебек, булачак тормыш иптәшен эзләп, полициягә мөрәҗәгать итүчеләр саны... уннан артык булып чыга.

Акчаны кире кайтарасы

Полициягә мөрәҗәгать иткән хатын-кызларның бары тик берсе – Елена Романова гына үзе белән килеп чыккан хәл турында язуга ризалык бирде. Калганнары суд хәлләрен туганнары, таныш-белешләре, хезмәттәшләре белүдән уңайсызланды.

Чыннан да гаҗәп бит: ике бала әнисе Алина Юналиева сайт аша танышкан чит бер ир-атка үз теләге белән 780 мең сум акчасын күчерсен әле! Ләйсән Вафина һәм Роза Сәгыйрованың да бар булган акчасы Алик Даниловны «вакытыннан элек төрмәдән чыгару»га китеп баруга ышанырлык түгел.

Ялгыз хатыннарны бәхетле итәргә ышандырган Алик Данилов үзе кем икән соң? Сак астында суд залына алып кергәнче, баһадир гәүдәле, чибәр ир-аттыр дип көткән идем. Башын иеп кергән ябык гәүдәле мескен кыяфәтле ирне күргәч, тагын да аптырый төштем. Бер ел дәвамында биш хатын-кызның башын әйләндереп, соңгы акчаларын алырга аны нәрсә мәҗбүр иткән?

Суд материалларыннан күренгәнчә, 1989 елда Түбән Кама шәһәрендә туып-үскән Алик Данилов, чыннан да, 2012 елда Мәскәү шәһәренең Дорогомилов районы суды тарафыннан Россия Федерациясе Җинаять кодексының 162 нче маддәсе нигезендә 6 елга иреденнән мәхрүм ителгән була. 2018 елда төрмәдән чыгарыла. Өйләнгән. Хатыны белән балигъ булмаган ике бала үстерәләр. Моңарчы Казандагы төзелеш оешмасында төнге каравылчы булып эшләгән.

– Төрмәдә утырганда карта уйнарга күнегеп киттем. Иреккә чыккач та әле картада оттырам, әле букмекер оешмаларына бурычлы булып калам. Откан чакларым да булды. Уйныйсы килә. Акча гел кирәк. Төн буе каравылда торганда телефоннан аралашып, вакыт та тизрәк уза, акча да килә тора, – дип сөйләде ул суд утырышында. – Төрмәдә төрле язмышлы кешеләр белән аралашырга туры килде. Игорь исемле берәү хатыны һәм баласының гомерен өзүдә гаепле кешене кыйнаган өчен утырды. Гел аралаша идек. Шул кеше сайт аша хатыннар белән танышып, алардан акча алуы турында әйткәләде. Хатыннар белән танышканда аның язмышын күздә тоттым.

Һәр медальнең ике ягы була. Кәрәзле телефон, интернет, сайт кебек заманча технологияләр кыек куллы мошенникларга гына хезмәт итеп калмый, ә алар кылган җинаятьләрне ачыкларга да ярдәм итә. Хокук сакчыларының берничә томлык тикшерү материалларында да алынган акчаның кемгә, күпме һәм кайчан бирелүе сәгате-минуты белән ачыкланган. Хәер, гаепләнүче моны үзе дә инкарь итми.

Лаеш районы суды, ачык утырышында әлеге җинаять эшен карап, Россия Федерациясенең 158, 159 нчы маддәләре буенча Данилов Алик Мирзанур улын гаепле дип табып, каты режимлы төрмәдә тоту шарты белән дүрт елга ирегеннән мәхрүм итте. Суд карарында әйтелгәнчә, алдау юлы белән алынган акча тулысынча кире кайтарылачак.

Камил СӘГЪДӘТШИН

ОЗЫН-ОЗАК ЯЛЛАРДА

ЯРЫШ БЕЛӘН ТӘМАМЛАНДЫ ҺӘМ... БАШЛАНДЫ ДА

Балтач

Кемгәдер гыйнвар каникулы бик озын, ялыктыргыч булып тоелгандыр. Бу кадәресе кешенең үзеннән дә тора. Ялларны туганнар, балалар, оныклар белән очрашулар өчен көтүче, шулардан зур сөенеч алучылар өчен аның күңел тынычлыгы биреп үтүе кадерле булса, актив тормыш алып баручылар бу каникулның бер көнен дә бушка үткәрмәде дип беләм.

Андыйлар алдан ук план корып, әзерләнеп көтә инде аны. Гаилә белән ял итәргә китү, сәяхәткә чыгу хәзер авыл җирлекләре өчен дә гадәтигә әйләнеп бара. Капка төпләрен, каралтыларын бизәп, үзләренә бәйрәм рухы тудыручылар да шактый.

Балтачта бу чорга бик күп төрле чаралар планлаштырылган иде. Күпчелек авылларда коймаклы-пылаулы тау-чана бәйрәмнәре, кышкы ярышлар, мәдәният йортларында авыл үзешчәннәре әзерләгән спектакль-концертлар, Яңа ел тамашалары, балалар белән төрле конкурсуеннар гөрләсә, спорт ярышларының нинди генә үтмәде!

Яңа елның беренче көннәрендә үк район газетасы призына 39 нчы тапкыр хоккей ярышлары башланды. Дүрт бозда ике көн дәвам иткән бу ярышлар районда бик популяр. Аларга төрле авыллардагы хоккей мәйданчыкларында район беренчелегенә ел да үткәрелүче «Алтын алка» ярышлары кушылды. Берсе – ел ахырында, икенчесе – елның беренче көннәрендә тантаналы төстә ачылган ике заманча хоккей мәйданчыгы да бәйрәм ялларында тынып тормады. Сүз уңаеннан, аларны төзүгә хуҗалыклар да зур өлеш кертте.

Бу елларда чаңгы трассалары, «Чана-Тау» трассасы да гөр килеп торды. Ярыштылар да, гаиләләр, дуслар белән дә шудылар, күңел ачтылар. «Сабантуй» ял паркында исә спорт сөюче гаиләләр эстафета ярышларында катнашты. «Факел» клубында «Форпост» оешмасы оештырган бәйгедә әтиләр һәм балалар пневматик мылтыктан, лазерлы мылтыктан атуда көч сынашты, «Тайгалак-шугалак» мәйданчыгында – себеркеле, авылларда итекле хоккей ярышлары, «Дулкын» бассейнында балалар һәм өлкәннәр арасында йөзү, Салавыч мәдәният йортында шахмат буенча район беренчелеге үтте. Әле күрше районнарда үткән спорт бәйгеләрендә катнашып, җиңүләр яуларга өлгерүчеләр дә булды.

Чепья авылыннан Сидоровлар ясаган сыннар.

«Ел спортчысы» бәйрәме һәм район башлыгы призына көрәш ярышлары белән тәмамланган ел әнә шулай спорт ярышларына бик бай булып башланды.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6943 данә
Гомуми тираж – 18156 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 202

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+